**«ЯНА СУЛЫШ»**

20 апрель көнне Бәзәәә мәдәният йортында авылдашыбыз, Алабуга мәдәният хэм сәнгать көллияте студенты Гүзәл Гатауллина «Яңа сулыш» дип исемләнгән концерт программасы белән чыгыш ясады. Гүзәлнең иҗатын яратучылар саны бик күп, алар районыбызның төрле авылларыннан, Менделеев шәһәреннән килделәр, 300 урынлык зал тулы иде. Тамашачы бу көнне рәхәтләнеп ял итте, җыр –моң диңгезенәә йөзде, шаярды, уйнады, күңел ачты.

Гүзәл кечкенәдән сәнгатькә гашыйк иде. Авылыбыз мәдәният йорты уздырган чараларда гел актив катнашты. Аның узенчәлекле, моңлы тавышы куплэрнең куңелен әсир итте. Бу Гүзәлнен тәүге концерты, ул быел Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятен тәмамлый. Биредә аның укытучысы Дәүләтов Илнур Мәгъсүмҗан улы да бар иде. Укытучысы киңәшләренә таянып, Гүзәл бик матур концерт программасы әзерләгән. Матур җырлар, дәртле биюләр, нәфис сүз, тамашачы белән шаян уеннар берсенәберсе үрелеп барды. Залда көчле алкышлар, яңгырап торды. Бу көнне Гүзәлне дебют концерты белән котлап, аның дуслары, курсташлары, Менделеев шәһәреннән «Шаян» халык бию ансамбле солистлары да килгән иде. Алар үзләренең чыгышлары белән Гүзәлгә матур киләчәк, иҗади уңышлар теләделәр.

Гүзәлнең хезмәтен югары бәяләп, тамашачы аны чәчәк букетларына төрде. Бәзәкә авылы җирлеге башлыгы исеменнән Гүзәлгә (Бәзәкә мәдәниятын үстерүдә, милли традицияләребезне саклап калуда керткән өлеше өчен) хэм укытучысы Илнур Мәгъсүмҗан улына (үз укучысының сәләтен күрә белүе һәм үстерүе, укуында һәм көллият эшчәнлегендәге барлык башлангычларын хуплавы өчен) РӘХМӘТ ХАТЫ тапшырылды

Әгәр бу концерт - Гүзәлнең имтихан эше булса, без авылыбыз, районыбыз белән берсүзсез

+5 ЛЕ БИЛГЕСЕ куябыз!

Гүзәл, мәдәният йорты коллективы исеменнән, авылыбыз халкына мәдәният өлкэсендэ хезмәт иткәнең өчен зур рәхмәт белдерәбез! Сиңа киләчәктә бары тик ак юллар гына телибез. Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә иҗади уңышларга ирешергә, яңа баскычлар, биек үрләр, зур жиңүләр яуларга язсын!

Г.Гөмәрова.

